УДК 930.2

# ЗИФА КАДЫРОВА ИҖАТЫНДА ХАТЫН-КЫЗ ОБРАЗЫНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

**Р. Р. Гаянова**
railya.nurly@mail.ru

*Набережночелнинский государственный педагогический университет*

***Аннотация (тат.):*** *З.Кадырова әсәрләрендә ятучы төп үзенчәлекләр. Кешеләрнең бәхет төшенчәсен аңлаулары. З. Кадырова геройларын утлар-сулар аша кичереп, һәркайсына үз хөкемен чыгаруы. Укучыларның аның китапларын бирелеп укулар*

***Аннотация (рус.):*** *Особенности рассказов З.Кадыровой. Понятие о счастье людей. Герои произведений З.Кадыровой в контекстах переживаний и представлений. Отношение к книгам через читательские интересы, женские образы в произведении З. Кадыровой*

***Ключевые слова (тат.):*** *З.Кадырова, татар теле һәм әдәбияте, үзенчәлекләр,хатын-кыз образы, матур образлар*

***Ключевые слова (рус.):*** *З.Кадырова, татарская литертарура,особенности, образы женщин, собирательный образ*

Теманың актуальлеге. Хәзерге татар әдәбиятының бер үзенчәлеге – бер дулкын булып мәйданга килеп кергән хатын-кыз язучыларыбыз иҗаты. Мәсәлән, өлкән прозаик Л. Ихсанова, фикерләү пөхтәлеге белән аерылып торучы М. Маликова, «Тулгак» повесте белән зур популярлык казанган Г. Галиева, әсәрләрендә хатын-кыз күңеленең, җанының иң ачы, авыр газапланулы якларын ачып сала алган Ф. Бәйрәмова, сәнгатьчә матур образлар, мавыктыргыч сюжетлар, борынгы мифологик мотивлар аша хатын-кыз образларын чагылдырган Н. Гыйматдинова кебек язучыларыбыз хәзерге татар прозасы күгендә әдәбиятыбызны, культурабызны үстерүдә зур өлеш керттеләр. Бу язучыларыбызга Ә. Ибрагимова, Д. Гайнетдинова, Ф. Аглиуллина, Э. Шәрифуллина, Р. Габдулхакова, Ф. Тарханова, Р. Рахман кебек әдипләр килеп кушылды. Хатын-кыз проза иҗаты мәйданында Зифа Кадырова да үз урынын алды.

Язучының татар телендә үзнәшер юлы белән дөнья күргән дүрт китабы, чын мәгънәсендә, укучылар мәхәббәтен яулады. 2008нче елда чыккан «Сагынырсың, мин булмам» һәм «Язмыш сынавы» китаплары икесе дә Татарстан Милли китапханәсенең «Ел китабы» исеменә лаек булды. 2010нчы елда «Көтеп узган гомер», 2013нче елда «Бәхеткә юл кайдан?» китаплары басылды. Шунысы игътибарга лаек: бу дүрт китапның һәркайсының тиражы – унбишәр мең данә. 2012нче елда өч мең данә тираж белән урыс телендә «Сумбуль» («Сагынырсың, мин булмам» повестеның тәрҗемәсе) китабы нәшер ителде һәм 2013 елда шулай ук «Ел китабы» исемен алды. Моннан тыш язучының әсәрләре «Ашзел» (Уфа), «Мәйдан» (Чаллы) журналларында, «Кызыл таң», дистәләгән район газеталарында дөнья күрде. Әлеге әсәрләре белән ул зур популярлык казанды. Хатын-кызның кичерешләрен сирәк ир кешеләр генә аңлый, әдәби әсәр аша тәңгәл җиткерә, әнә шуңа күрә әдәбиятыбызның үзәккә кеше язмышы, хисләре куелган һәр китабын диярлек татар укучысы үз итә. Әдәбият сөючеләрнең күпчелеге хатын-кыз булу бәхәс уятмыйдыр дип беләбез. Ул исә үзенә якынны, чын тормышны реалистик буяуларда чагылдырганны үз итә. «Аның әсәрләрендә башларны югалтырлык кайнар мәхәббәт, көтелмәгән хыянәт, тормыш юлларындагы ялгышлар, тетрәнүләр, газаплар, ачы югалтулар һәм татлы күз яшьләренә манчылган бәхетне табу мизгелләре. З. Кадырова кеше язмышларын аяусыз тикшерә, геройларын утлар-сулар аша кичереп, һәркайсына үз хөкемен чыгара. Китапларының яратып укылуының сере шундадыр», дип яза Ф. Садриев. [13, Б.5] Тик нәфис әдәбият белән дус булганнар арасында, әлбәттә, мондый җиңел язылган һәм җиңел укылган әсәрләрдән укып канәгатьлек ала алмаучылар да табыла.

Шуңа да Зифа Кадыйрованың әсәрләрен язучылар һәм тәнкыйтьчеләр нәфис әдәбият әсәре буларак кабул итә алмый интекте. Әмма аларның укымлы булуын, үз укучыларын табуын, әллә ничәшәр кат яңадан басылуын беркем дә инкарь итә алмый. Теманың актуальлеге шуның белән билгеләнгән.

Фәнни эшебезнең максаты – З.Кадырова иҗаты мисалында хатын-кыз прозасының үзенчәлекләрен ачыклау.

Максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар куелды:

1. З.Кадырова иҗаты һәм тормыш юлын өйрәнү.

2. З.Кадырова иҗатына хас төп үзенчәлекләрне билгеләү.

Фәнни эшебезнең структурасы: кереш, төп өлеш, йомгаклау, кулланылган әдәбият исемлеге.

Керештә теманың актуальлеге, төп максат һәм бурычлар куела.

Төп өлешнең беренче бүлеге Зифа Кадырованың тормыш һәм иҗат юлына, төп иҗади үзенчәлекләренә багышланган.

Икенче бүлектә без турыдан-туры темага караган фикерләребезне туплап, З.Кадырованың әсәрләрендәге хатын-кыз образының үзенчәлеген «Сагынырсың, мин булмам» һәм «Язмыш сынавы» повестьлары нигезендә анализладык.

Йомгаклау бүлегендә хезмәтнең нәтиҗәләре билгеләнгән.

**Бүлек 1 З.Кадырованың тормыш юлы һәм иҗаты**

Зифа Әбделвәли кызы Кадырова 1958 елның 7 октябрендә Башкорстанның Учалы районы Ахун авылында дөньяга килә.

Башкортостан кызы Чаллы якларына, КамАЗ төзелә башлагач, комсомол путевкасы белән килә. Мөслим районы егете Марсель өйләнешеп, уллары Русланны, кызлары Регинаны тәрбияләп үстерәләр. Төзелештә маляр, диспетчер булып эшли. Заводта кыскартулар башлангач, эшсез калган чаклары да була. Бүгенге көндә хаклы ялда. Ир-егетләр эшен башкаручы бу ханымның халык шулай егылып укырдай тормышчан, гыйбрәтле язмышлы әсәрләр иҗат итүе гаҗәп тә, серле дә кебек. Югары белем дә алмаган, яшьтән дә бернәрсә дә язмаган З. Кадырова кулына каләмне 48 яшендә генә ала.

З. Кадырованың кулына каләм алып әсәрләр яза башлавына бик күп булмаса да, аның «Сагынырсың мин булмам», «Язмыш сынавы», гомер буе кемне дә булса көтеп яшәргә мәҗбүр Фатыйма, каты авырудан һәм хыянәт ачысыннан сыгылып төшәргә ашыкмаган Рушания, чәчләренә чал төшкәнче тәүге мәхәббәтен уйлап яшәгән Асылгәрәй язмышын бер китапка туплаган «Көтеп узган гомер», күптән түгел генә дөнья күргән «Бәхеткә юл кайдан?» повестьлары укучылар тарафыннан яратып кабул ителде.

«Сагынырсың – мин булмам» повесте беренче тапкыр 2009 елда «Мәйдан» журналында басылып чыга, 2012 елда ул үзешчән театр тарафыннан сәхнәләштерелеп халыкка күрсәтелә, шулай ук рус теленә тәрҗемә ителеп «Сумбуль» исемендә дөнья күрә.

«Бәхеткә юл кайдан?» дип исемләнгән повестенда да автор башларны югалтырлык кайнар мәхәббәт, көтелмәгән хыянәт, тормыш юлларындагы ялгышлар, тетрәнүләр, газаплар, ачы югалтулар һәм татлы күз яшьләренә манчылган бәхетне табу мизгелләрен сурәтли. Һәркемне дулкынландыручы мәңгелек проблемаларга тугры калган З. Кадырованың бу әсәре алда язылганнарыннан да зуррак резонанс алыр кебек. Аның бәхете һәм аны табу турындагы уйланулары укучыга төгәл концепция рәвешендә җиткерелә.

З. Кадырова әсәрләрендә укучыны үз бәхетең өчен гомер буе көрәшергә кирәк дигән максат куеп яшәргә, кичерә белергә, үчләшмәскә өнди. «Хатын-кызның тормышны җигелеп тартуы, ләкин бервакыт тәмам алҗап егылуы, кайбер әзмәвердәй ир-атның хатынының арык җилкәсе артына гына ышыкланып яшәве, аларның көчсезлеге борчый мине. Тормыш дилбегәсен ирләр каты кулларында тотарга, ә хатын-кыз сабыр акыллы һәм зирәк булырга тиеш дип чаң сугам әсәрләремдә. Китапларымны укыган һәркем үзенә сабак алсын, башкалар ялгышы гыйбрәт булсын, язмыш сынауларына бирешмәсен иде дигән максат куеп язам»,– ди язучы. [7, Б.3]

Зифа Кадыйрованың төп укучысы – хатын-кыз, ә хатын-кыз дөньясында хис-тойгы, эмоция, кичерешләр өстенлек итә. Шундый тональлеккә корылган әсәрләрне хатын-кыз яратып укый. Юкка гына «хатын-кыз романы», «мәхәббәт романы», «сентименталь роман» кебек серияләр белән китап кибетләре тулмагандыр. Ә татар әдәбиятында бу жанрлар киң үсеш алган дип булмый. Димәк, Зифа Кадыйрова шул бушлыкны тутыручы, эшкәртүче ролендә чыгыш ясый. Зифа Кадыйрованың герое - бик катлаулы тормыш юлын үткән, шул юлда табыш-югалтулар аша үз бәхетен тапкан хатын-кыз. Ул көчсез көчле, йөрәк акылы белән акыллы, сынарга тиештә дә сынмаучы, бу дөньяга бирешми үз оясын коручы. Шуның белән ул укучыны җәлеп итә, чөнки китап уку барышында без: «Син кем? Синдә мин бармы? » – дип укыйбыз, геройлар язмышын үз тормышыбызга, үз язмышыбызга «үлчәп» карыйбыз, китап белән эчке диалог алып барабыз. Автор һәм укучы мөнәсәбәте нигезендә уртак дөнья туа, әсәр һәр укучының үз тарихы белән тулылана, баеп китә. Зифа Кадыйрова китабы бүгенге катлаулы, заманда «җан табибы» ролен башкара булса кирәк. Китапның гади булуы да укучыны җәлеп итүче фактор. Ул әзерлексез укучының да «теше үтәрлек» итеп язылган.

Автор геройларның рухи халәтен оста күрсәтеп, кеше күңеленең нечкәлеген һәм катлаулыгын тирәнтен ачарга тырыша. Әсәрдә фикер тыгызлыгы, сюжет төзеклеге, телнең чарланган, тормышчан булуы белән бергә әхлаклылык, мәрхәмәтлелек һәм шәфкатьлелеккә өндәү дә сизелә. Билгеле, болар – язучының осталыгыннан, тормышны тирән белүеннән килә. Язучының тагын бер осталыгы – иң тирән кичерешләрне дә, гади һәм аңлаешлы итеп ача белүе. Укучы моны югары бәяли.

З.Кадырова китаплары да нигездә «хатын-кыз романы» рәвешендә кабул ителә. Аның әсәрләрендәге төп тема – мәхәббәт темасы. Хатын-кыз дөньяга яратыр һәм яратылыр өчен, кешелек дөньясын киләчәккә бәйләр өчен килә. Аналык вазифасын үтәп, гаилә иминлеген саклап калу, балаларны үзенә лаеклы алмаш итеп үстерү өчен күпме ихтыяр көче кирәклеген гүзәл затларыбыз үзләре генә белә. Бүгенге заман хатын-кызларының төп өстенлеге һәм бәласе нәрсәдә сон? «Бүгенге хатын кызларның өстенлеге дә төп бәләсе дә, артык көчле булудадыр, бу 90 елларда башлангандыр бәлки, халык эшсез акчасыз калганда да хатыннар гаиләне тартып чыкты, ә ирләр шул көчне күтәрә алмый ташлап китте, кайберәүләр шул хатын сыртында утырып калды. Менә шул өстенлек үзе бер бәхетсезлек, көчле ир белән иркә хатын булып яшәсә ул күпкә бәхетле булыр иде, тик ирләр башкача уйлый. Ир ир урынында булырга тиеш. Хатын-кыз гаиләдә баш булса ир бала йомшак була, шулай булгач киләсе буынга чын көчле ир килә аламы?» – дигән сорауга җавап эзли З.Кадырова үзенең әсәрләрендә. [5, Б.8]

Бу дөньяда яшәүче һәр кешенең бар булган мәхәббәт көче белән яраткан, аның өчен гомерен бирергә әзер булган әйбере буладыр. Чөнки кеше бу җиһанда, һичшиксез, нәрсә өчендер яши. Һәркем өчен дә шундый зур хәзинә, дөньяда булган барлык асылташларга да алыштырмаслык нәрсә бар. Ул – яраткан, бердәнбер гаилә. Адәм баласы нинди генә авырлыклар кичереп яшәмәсен, гаиләсендә нинди генә катлаулы мөнәсәбәтләр булмасын, аның йөрәк түрендә барыбер гаиләсенә карата булган җылылык саклана. Бу җылылык бик көчле булырга мөмкин. Әлеге җылылык, йөрәккә генә сыймыйча, бар булган якын кешеләренә аз гына булса да өлешен бүләк итеп, аларга дөньяда яшәргә көч биреп, үзенә бертөрле ямь өстәп торырга мөмкин. Гаилә ул – тормышның нигезе. Әтиәни аның тоткасы булса, балалар – гаиләнең көзгесе. Әгәр тотка купмасын, ватылмасын дисәң, бер-береңне аңлап, хөрмәт итеп яшәргә кирәк. «Гаилә бит ул шул мәхәббәт дигән нәрсәдән корыла. Тик мәхәббәт дигән нәрсә күп кырлы ике ташны хәтерләтә, хис, тойгы, барысы да бар. Алар бер-берсенә яраклашып чуер ташка әйләнгәнче күпме еллар үтә, мәхәббәтне саклар өчен бик зур сабырлык кирәк. Ходай кешене читтән шашкын хисләр биреп сыный, ә бу чир, авыр чир, күпләр шул чиргә каршы тора алмый мәхәббәтен дә югалта. Хатын –кыз бит ул гаилә учагын саклаучы, ул җылы булса гына барысы да аның янына җыела.», – ди З.Кадырова. [14, Б.12] Әсәрләрендәге хатын-кыз образлары аша да ул сабыр булырга, ялгышларны, гөнаһларны кичерә белергә чакыра.

Бәхеткә юл авырлыклар аша бирелә. Бераүләр исә шул авырлыкларга каршы тора алмыйча упкынга тәгәри. Ә икенчеләре исә алга таба да үзендә яшәргә көч табып, биек үрләрне яулый. З.Кадырованың «Язмыш сынавы» һәм «Сагынырсың, мин булмам» дигән 2 әсәре дә моның ачык мисалы. Әлеге иҗат җимешләрендә автор нәкъ менә шул фикерне алга сөрә, тормышның һәрбер мизгеленнән тәм табып яшәргә, аның кадерен белергә, язмыш тарафыннан бирелгән сынаулар алдында югалып калмаска чакыра. «Кеше рәхәт яшәр өчен генә тумый шул, аның һәр көне көрәш.» [2, Б.148]

З.Кадырова әсәрләрендә төп геройларны бер уртак сыйфатлар берләштерә: хатын-кызлар гади, эчкерсез, изге күңелле, чибәр һәм миһербанлы, үзләренә якын булган кешеләрне бөтен җаннары белән яраталар, хәтта үзен күралмаган затларга да ачу сакламыйлар, кичерә белү сәләте бар аларда.

«Язмыш сынавы» – тормыштан алынган вакыйгаларга нигезләнеп язылган. Әсәрнең сюжеты бик күп еллар аралыгын колачлый. Аның яз ел фасылы белән башлануы да юкка түгел, безнеңчә. «Бар тере җанның күңелен җилкендереп, һавада мәхәббәт дулкыннары йөзә», – дип яза язучы. [2, Б.5] Нәкъ менә шундый вакытта, табигатьнең яшәреп яшеллеккә күмелгән чагында Таһир белән Әлфия арасында сөю ялкыны кабына. Егетне озату кичәсенә килгән йөргән кызы Мөнирәнең нәрсәгә сәләтле икәнен генә бераү дә күз алдына китерми бу вакытта. Ә Таһир Әлфиянең җирән чәчләренә, сихри яшел күзләренә гашыйк була. Автор да әсәрнең буеннан буена шушы яшел төймә кебек күзләргә һәрдаим басым ясап тора. Күзләргә карап, кешенең бөтен күңел халәтен, шатлыгын да, борчуын да күрсәтергә омтыла. Әсәрдән китерелгән түбәндәге җөмләләр моңа дәлил: 1) «Чәчләре хәзер калын бөдрә булып иңнәренә төште, яшел күзләрдә яшәү теләге кабынды.» [2, Б.106] 2) «Чөнки олы яшел күзләрдә шундук хафалану барлыкка килә.» [ 2, Б.170]

Әлфия – «Язмыш сынавы» әсәрендә хатын-кызлар арасында төп образ. Китапны укый башлау белән, аның иң матур сыйфатларының берсе күзгә ташлана, ул да булса тугрылык. Үзе артыннан бер көтү егет йөрүенә карамастан, Таһирга биргән вәгъдәсенә тугры кала ул. 2 ел буена бераүне дә якын китерми. Хәтта Мөнирә тараткан гайбәт сүзләре дә аларның хисләренә киртә була алмый. Армиядән кайтып, Әлфия белән якыннанрак аралаша башлагач, Таһир аның хыялында йөрткән хатын-кыз икәнлегенә тагын бер кат инана һәм ялгышмый да. Беренче курсны тәмамлап, өйләнешкәч тә аларның бер-берсенә карата булган сөю хисләре тагын да ныграк арта.

«Таһир белән Әлфиянең тормышы карап туймаслык иде: ике елда ике кода тырышлыгы белән зур матур өй җиткерделәр, аны Таһир төзегән план белән заманча итеп эшләделәр, бер дә шәһәр фатирыннан ким түгел, бик шәп чыкты.» [2, Б.40] Бик бәхетле булалар алар: яннарында мәхәббәт җимешләре – 2 улы Заһир белән Әлфис үсеп килә, яраткан эшләре, һәрвакыт ярдәм кулы сузарга торган әти-әниләре бар. Тик кеше бәхетеннән көнләшеп, шул бәхетне җимерер өчен теләсә нинди адымга барырга әзер булган кешеләр дә очрый тормышыбызда. З.Кадырова да әлеге әсәрдә Әлфиягә бөтенләй капма-каршы булган Мөнирә образын тудыра. Китапның беренче битләреннән үк аның нинди үчле кеше икәнен аңлыйбыз. Таһир белән Әлфиянең арасын бозар өчен, егет армиядә чагында ялган сүзләр тарату белән башланып китә аның мәкерле планы. Аннан укырга китеп, тулай торакта яши башлагач, кызлар арасында мондый сүзләр тарата: «Таһир белән киного, танцыга бардык. Ул мине һәрвакыт озатып куя, кичә дә аның бүлмәсендә утырдык та, мине озата килде. Кайтырга соңга калгач, минем бүлмәдә кунып китте...»[2, Б.22] Ә чынында исә юкны бар итеп үзе килеп йөри башлый Мөнирә. Бер-берсен улеп яраткангамы, аның сүзләренә ышанмыйлар алар. Туй мәҗлесендә бәхетле парларны күреп, тагын та явызрак планнар кора ул. Кешегә эшләгән начарлыклар кайчан да булса үзенә әйләнеп кайтачагын, шушы бер хата тормышын төбе-тамыры белән үзгәртер дип башына да китерми Мөнирә. Илдусның исереклегеннән файдаланып, аны үз өенә алып кайта, көчләде дип ялганлап, аны үзенә өйләнергә мәҗбүр итә. «Бу – Мөнирәнең беткә үч итеп тунны ягуы иде. «Янында да булмам, ерак та йөрмәм. Бервакыт барыбер мине күрерсең,

җирән марҗага өйләнгәнеңә үкенерсең», – дип тешләрен кысты.» [2, Б.27] Ничәмә-ничә кешене газап утларына сала ул: Илдус алдында үзен гаепле санап гомере буена газапланып яшәгән әнисен, нәфрәт хисләреннән яралган гарип баласы Ильясны, бәхетсез тормышында гаепләп, җан дустыннан баш тарткан Илдусны һәм сөйгәнен югалту ачысын үз иңнәрендә күтәргән, шул газапларны күтәрә алмыйча, күпмедер гомерен газиз балаларыннан читтә, җүләрләр йортында уздырган Әлфияне. «Шулай, ир иткән дә хатын, юк иткән дә хатын – борынгылар белми әйтмәгәннәр.» Нәкъ менә шуны исбатларга тели сыман З.Кадырова «Язмыш сынавы»ндагы әлеге образлар белән. Илдусның гарип бала караулары, Мөнирәнең үз баласын бер тапкыр да кулына алмавы, алардан көлеп, җирәнеп яшәве, башка берәүдән туган ак башлы малае Рөстәмдә башкаларга карата шундый мөгамәлә тәрбияләве җан өшеткеч итеп сурәтләнә, Илдусның һәм шул бер гөнаһсыз сабыйның тилмерүләрен күреп йөрәк әрни. Ничә тапкырлар 15 көнгә илтеп яптыра ул Илдусны, хәтта төрмәдә дә утырып чыга. Баласының берүзе ачка тилмереп җан биргәненнән соң да үзгәререп тә карамый Мөнирә. Киресенчә, «баланы үтереп, пенсиясез, фатирсыз калдырдың», дип Илдусны гаепли.

Мөнирәнең гөнаһлары бик күп, шулар арсында иң зурысы – Әлфиягә дип бозым ясатудыр, мөгаен. Яраткан тормыш иптәшен югалту, шул кайгыдан җүләрләр йортына эләгү дә шуның нәтиҗәсе. Вакытында табып алмаган булса, Әлфиянең балалары тома ятим калырлар иде. Уйлап карасаң, никадәр кансызлык, мәкерлек, явызлык, нәфрәт сыйган шушы бәндәгә. Кешеләргә китергән авырлыклар үз башына төшкәч тә, алар белән көрәшеп-нитеп тормый ул, Рөстәмне кайчандыр күрә алмаган Әлфия белән Илдус тәрбиясенә калдырып, үз-үзенә кул сала.

Шушы бер-берсенә капма-каршы булган Әлфия һәм Мөнирә образлары аша З. Кадырова яхшылык һәм яманлык, ак белән кара, мәхәббәт һәм нәфрәт көрәшен ачып бирә.

Әсәрләрендәге уңай хатын-кыз образларына ул тагын бер күркәм сыйфат – сабырлык иңдерә. «Иң беренче урында хатын-кыз сабырлыгы. Хатын-кызның бала тәрбияләве төп урынны алып тора. Әсәрләремдә кичерә белү дигән әйберне беренче урынга куям. Бу – ялгышларны, гөнаһларны кичерә белү. Исән кеше хата ясамый тормый. Хатын-кыз кичерә белергә, сабыр булырга тиеш. Мәхәббәт бер көнлек түгел. Сабыр көткән кеше һәрвакыт үз морадына ирешә.», – ди З. Кадырова. [10, Б.17] «Язмыш сынавы»ндагы Ләйсән образындагы сабырлык та зур соклану уята. Институт бетереп, шул авылга укытучы булып эшкә кайткан әлеге яшь кызның армиягә китеп барган Рушанга карата мәхәббәте шулкадәр көчле була ки, егетенең ике аягын югалтып кайтуына карамастан, аны кире какмый, өметен өзми ул; киресенчә, аны тизрәк аякка бастыру өчен кулыннан килгәннең барысын да эшли. Рушанның өзгәләнүләрен күңелгә тиярлек итеп сурәтли З. Кадырова. Аның, мин бәхетле итә алмаячакмын дип, кире кагуларын, куып чыгаруларына да үпкәләми Ләйсән. Нинди генә очракта да үз-үзен тыныч тотуы, киләчәккә зур өметләр баглавы, ягымлы, җылы сүзләре Рушанның әти-әнисенә дә зур юаныч була. «Сабир абый, ул бит аяксыз гына, башсыз түгел, ә аякларга протез ясыйлар. Сез нәрсә кайгыга батып утырасыз? Бар да яхшы булыр. Минем бабам да сугыштан аяксыз кайткан, әбием биш бала тапкан. Алар бик матур яшәгәннәр.» [2, Б.194]. Менә нинди көчле рухлы, сабыр, түзем, язмыш сынаулары алдында югалып калмый торган образлар тудыра З.Кадырова. Аларның һәрберсе безне уйланырга мәҗбүр итә, үзебездә булган начар сыйфатларны юкка чыгарырга чакыра, тормышка, кешеләргә башка күзлектән карарга өйрәтә.

«Язмыш сынавы» әсәрендәге тагын бер «замана» образы бар. «Гүзәл – районда иң бай кешенең кызы. Кыз чынлап та гүзәл зат, шуның өстенә үз-үзенә бик ышанучан, башкаларга өстән аска карарга ярата. Укуга да исе китмәде. Егетләр белән үзен бик иркен тота, кайсын теләсә, шунысын каптыра.» [2,Б.173]. Балда-майда йөзеп, рәхәттә генә яшәп күнеккән әлеге кызга тормыш шулай ук кырыс тәрбиясен бирә. Үч алу теләге белән,

Сафуан аны харап итә, нәтиҗәдә Гүзәл авырга уза. Һәм кешеләр алдында хурлыкка калмас өчен, әтисенең ышанычын югалтмас өчен, ул Рөстәмне үзенә өйләнергә мәҗбүр итә. Кызлары Гөлназ тугач та, алар арасындагы мөнәсәбәтләр үзгәрми, киресенчә кискенләшә төшә. Гүзәл баласын карамый, ә Рөстәм бер гөнаһсыз Гөлназны үз баласыдай тәрбияли. Кешенең хисләренә көлеп кенә карарга өйрәнгән Гүзәл көннәрдән беркөнне кайчандыр күралмаган Рөстәмгә чын-чынлап гашыйк була. Һәм менә шул бөек мәхәббәт аңарда аналык хисләрен дә уята. Автор моның белән мәхәббәтнең барлыгын һәм аның кешене яшәтүче көч икәнен тагын бер кат исбатларга тели сыман.

Гомумән алганда, «Язмыш сынавы» эчтәлеге ягыннан да, образлар ягыннан да халыкчан булуы белән игътибарга лаек. Анда әллә нинди катлаулы сюжет сызыклары да юк кебек. Язмыш сынауларын җиңәргә көч тапкан Әлфия, аны мәңгелеккә ташлап киткән Таһир һәм гомере буе алардан көнләшеп, аларның арасын бозарга өметләнеп йөргән Мөнирә образлары һәр кешен уйландыра, тетрәндерә. Әтиләре үлгәннән соң аның зиратына килеп, кабер өстендәге туфракларны тырный-тырный елап утырган хатын, әниләре акылдан шашуын күреп үзләре дә инде авыру дәрәҗәгә җиткән сабый балалар, аларның да зиратка килеп кабер өстендә тәгәри-тәгәри елаулары, «әти, кайт инде» дип өзгәләнүләре укучыны тетрәндерә һәм тормыш кадерен белергә, мәхәббәтне олыларга өйрәтә. Шул ук вакытта безнең янәшәбездә кеше бәхетеннән көнләшүче, аларның бәхетеннән өлеш өмет итеп йөрүче Мөнирә кебек кешеләр дә бар. Кешеләргә начарлык теләгән очракта аның күпмедер вакыттан соң үз башыңа әйләнеп кайтачагы турында кисәтергә тели автор.

«Сагынырсың – мин булмам» әсәренең исеме үк үзенә тартып тора торган, кызыксындыра, җәлеп итә һәм бөтен эчтәлекне бер сүз белән әйтеп бирә.

Әлеге повестьның төп герое – Сөмбел – кечкенә буйлы, нечкә билле, озын чәчле, кыйгач кашлы, һәрвакыт елмаеп йөри торган сөйкемле кыз. Әсәрнең башында ул шулай сурәтләнә. Әлегә ул тормышны аз күргән, әнисе канаты астыннан чыкмаган, әллә ни чибәр дә булмаган кыз бала. Әсәр дәвамында бу кыз төрле авыр сынаулар аша горур үтеп, тормышта үз юлын, үз урынын таба, кешеләр арасында абруй казана.

Һәркем бу дөньяга бәхетле яшәргә килә, ләкин бәхет беркемгә дә җиңел бирелми, Сөмбел дә бәхете өчен көрәшә. Төрле кыенлыкларны җиңеп чыгып, үзенең кешелеклелеге, дөреслеге, яхшыга яхшы була белгән изге күңелле кешеләрнең ярдәме аркасында таба ул бәхетен. Авырлык белән тапкан бәхетен күз карасыдай саклый да белә Сөмбел. Аның бәхете – гаиләсе. Сине яратып, синең өчен җан атып торган ирең, сау-сәламәт балаларың янәшәңдә булудан да зуррак бәхет юк хатын-кыз өчен. Сөмбел образы аша язучы шуны күрсәтергә тели.«Сагынырсың – мин булмам» әсәрендә Сөмбелдән чәчәкләр утырттырдым. Үзеңнән соң якты эз, матурлык калдыр, син юкта сине сагынып искә алсыннар дигән фикерне уздырырга тырыштым.», – ди З.Кадырова. [10, Б.17]

Кыска буйлы, чибәрлеге белән дан тотмаса да, бик күпләрнең мәхәббәтен яулаган Сөмбел образының капма-каршысы итеп, зифа гәүдәле, искиткеч чибәр Фәридә тасвирлана. Ләкин никадәр генә чибәр булмасын, тышкы матурлыгы аңа бәхет китерми. Әлеге ике образ аша язучы тышкы матурлыкка караганда эчке матурлыкның күпкә мөһимрәк булуын, бала табу фигурамны ямьсезли, диюче Фәридә аша «хатын-кызның бөтен күрке, бөтен матурлыгы – ана булуда» икәнлеген ассызыклый, моны бик уңышлы тормышчан мисаллар ярдәмендә дәлилли.

Әлеге китапта Сөмбелгә бәйле рәвештә бертуган Арслановларнарның тормыш юллары, язмышлары тасвирлана. Автор зур борылышлар, тирән кичерешләр аша бу гаиләнең гомер юлын яктырта. Шәүкәт абый белән Гөлфия апа – изге күңелле, тырыш, дөреслек яклы кешеләр. Улларына матур үрнәк гаилә булып яшиләр. Әсәр агышында әлеге гаиләгә гашыйк булганыңны сизми дә каласың, кызы булган һәр ата-ана үз нарасыен нәкъ шундый гаиләгә килен булып төшсә иде дип, уллары булганнар, минекеләр дә Байрас, Азамат шикелле уңган, көчле рухлы булсыннар иде дип хыяллана. Кызлар исә,

тормыштан шундый егетләр эзли. Кыскасы, китапны укыган һәркем аларга сокланып карый, җир йөзендә мондый гаиләләрнең күбрәк булуын тели.

Гомумән алганда, Зифа Кадыйрованың геройлары – күбесе горур, язмыш сынауларында сынатмыйча, күңел сафлыгын саклап, кешелеклелек, миһербанлык сыйфатларын югалтмыйча, тормышта үз урыннарын тапкан, һәм шул ук вакытта, гади кешеләр. Аларның күбесе җебегән, яисә мескен кешеләр түгел бит. Бу, безнеңчә, авторның үзенең холкыннан, аның гаиләсен яратуы, киләчәкне, милләтебезне бәхетле итеп күрергә, кешеләргә гаилә бәхетенең бөтен нәрсәдән дә өстен торуын күрсәтергә теләвеннәндер. Үзе шундый уңай сыйфатларга ия булмаган кешенең күңелендә, меңәрләгән укучыны әсир итәрдәй образлар туа алмый.

З. Кадырова әсәрләрендә хатын-кыз сабырлыгы, сынауларга дучар ителгән яралы язмышлар, шатлыгын да, газабын да үзенә сыендырган мәхәббәт – төп темаларның берсе булып тора. Язучы һәрдаим уй-тойгыларын, әйтергә теләгән фикерен образлы, үтемле итеп яңгыратырга омтыла. Сызлану, ачыну аша яхшылыкка, бер-береңне аңларга чакыра, бу чакыру сүз текст аша гына түгел, бәлки җан тирбәлешенә корылган ачыну, моң аша алып барыла. Ул әсәрләрен фәлсәфәгә кормыйча, табигать күренешләрен сурәтләү белән мавыкмыйча, тел сурәтләү чараларына тирән кереп китмичә, гади, аңлаешлы итеп яза, шул ук вакытта, хатын-кыз тормышын чагылдырган әсәрләргә сусаган укучының күңелен тибрәтә, китапка карата кызыксындыру уята. Автор образларны, вакыйгаларны сиземлерәк итеп сурәтли, аларга үзенчәлекле төс кертә, әсәр теленең халыкчанлыгын, гадилеген, аһәнле яңгырашын тәэмин итә. Үзәк героиня образларын тудырганда З. Кадырова үзен оста портретчы итеп тә таныта, героиняларын гомумән татар кызларына хас күркәм сыйфатлар белән күз алдына бастыра. Моңа кадәр без Ә.Еники, Ф.Садриев әсәрләрендәге хатын-кыз сабырлыгын тасвирлаган әсәрләр белән таныша идек. Зифа Кадырова әсәрләрендә дә кайбер хатын-кызларга гына хас түземлелек, сабырлык, нинди генә кайгы-хәсрәт килгәндә дә түзеп, үз җилкәсендә күтәргән хатын-кыз образы белән тагын бер кат танышабыз.

Шулай итеп, З.Кадырова иҗатына хас үзенчәлекләр, аның әсәрләренең укучы күңелен яулап алу сәбәпләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. Сюжет төзи белү осталыгы. Язучы әсәрләренең күпчелеге реаль тормыштагы вакыйгаларга нигезләнеп язылган. Һәрбер укучы китапның эченә кереп, аның геройлары белән бергә шатлана, борчыла, һәркайсына үз хөкемен чыгара. Шулай итеп, З. Кадырова әсәрләре – кеше рухының тирән катламнарына үтеп керә алырлык, дип әйтә алабыз;

2. Язучы гади сөйләм теленә нигезләнә, аның тәмен тоеп, сүзләрнең тере кулланылышта булган бар мәгънә төсмерләрен белеп яза, ягъни халык белән бер телдә сөйләшә. Әсәрнең аңлаешлы булуы, халыкчанлыгы, әлбәттә инде, һәр укучыны үзенә җәлеп итә.

3. Автор геройларның рухи халәтен оста күрсәтеп, кеше күңеленең нечкәлеген һәм катлаулыгын тирәнтен ачарга тырыша. Әсәрләрендә фикер тыгызлыгы, сюжет төзеклеге, телнең чарланган, тормышчан булуы белән бергә әхлаклылык, мәрхәмәтлелек һәм шәфкатьлелеккә өндәү дә сизелә. Язучының тагын бер осталыгы – иң тирән кичерешләрне дә, гади һәм аңлаешлы итеп ача белүе. Укучы моны югары бәяли.

4. Зифа Кадыйрованың төп укучысы – хатын-кыз, ә хатын-кыз дөньясында хистойгы, эмоция, кичерешләр өстенлек итә. Шундый тональлеккә корылган әсәрләрне хатын-кыз яратып укый. Ә татар әдәбиятында «хатын-кыз романы», «мәхәббәт романы», «сентименталь роман» кебек жанрлар киң үсеш алган дип булмый. Димәк, Зифа Кадыйрова шул бушлыкны тутыручы, эшкәртүче ролендә чыгыш ясый.

5. Зифа Кадыйрованың герое – бик катлаулы тормыш юлын үткән, шул юлда табышюгалтулар аша үз бәхетен тапкан хатын-кыз. Ул көчсез көчле, йөрәк акылы белән акыллы, сынарга тиештә дә сынмаучы, бу дөньяга бирешми үз оясын коручы. Шуның белән ул укучыны җәлеп итә, чөнки китап уку барышында без геройлар язмышын үз тормышыбызга куеп карыйбыз, китап белән эчке диалог алып барабыз. Шул аралашу барышын-

да геройларның да гади җир кешесе икәнлекләрен, син-мин кичергәннәрне кичергәнен күрәбез. Автор һәм укучы мөнәсәбәте нигезендә уртак дөнья туа, әсәр һәр укучының үз тарихы белән тулылана, баеп китә.

6. З.Кадырова әсәрләре инстинктлар дәрәҗәсендә милли аңга (подсознаниегә) юнәлтелгән. Алар яшәеш омтылышының көчлелеге, оптимизм хисе, матурлыкны тою һәм гүзәллеккә тартылу хисе белән үтәдән-үтә сугарылган. Язмыш сынауларына бирешмичә, алга атлаган геройларны һәрвакыт бәхетле киләчәк көтә.

### Литература

Чыганаклар:
1.Кадырова, З. Сагынырсың, мин булмам. – Казан: Идел-Пресс нәшр., 2011. –304 б.
2. Кадырова, З. Язмыш сынавы. – Казан: Идел-Пресс нәшр., 2012. – 336 б.
Фәнни-теоретик әдәбият:
3. Әдәби әсәр өйрәнәбез һәм анализ ясыйбыз/ Д.Ф.Заһидуллина, М.И.Ибраһимов, В.Р.Әминева. – Казан: Мәгариф, 2007.
4. Әхмәдуллин, А.Г. Әдәбият белеме сүзлеге. Татарстан китап нәшр.,1990.
5. Әхмәтгалиева, А. Эзегездән гөлләр үсеп калсын// Сөембикә. – 2011. – №6. – Б. 36-38.
6. Гасыймова, Р. Кешеләргә гадилек тә тансык...// Шәһри Чаллы. – 2011. – 30 март.
7. Зарипова, Р. Кичерә белегез, үчләшмәгез// Әгерҗе хәбәрләре. – 2013. – №10. – Б. 8.
8. Закиров, Л. Көчсез ир белән яшәү кызык түгел"// Татарстан. – 2016. – №3. – Б. 62-64.
9. Миңнуллин, Ф. Балта явызлар кулында: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татарстан китап нәшр., 1994. – 344б.
10. Рәхимова, Б. Әдәпле әдәбият// Шәһри Казан, – 2002. – 2 авг.
11. Сәетгәрәева, Р. Җаным кайгыдан түгелде...// Якты юл. – 2010. – 17 февр.
12. Татар әдәбияты: Теория. Тарих/ Д.Ф.Заһидуллина, Ә.М.Закирҗанов, Т.Ш.Гыйләҗев, Н.М.Йосынова. – Тулыл. 2нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006. – 319б.
13. Хәзерге татар прозасы. – Казан: Татарстан китап нәшр., 2007. – 671б.
14. Хәлиуллина, З. Укучылар төзүчене ярата, ә язучылар? // Шәһри Казан. – 2012. – №12. –2 фев. – Б. 20.
15. Хәмидуллина, Р. Бәхеткә юл кайдан?..// Яшел Үзән. – 2013. – 19 июнь.
Электрон ресурслар:
16. Айгөл Әхмәтгалиева: Элек халык мәхәббәте терәк булгандыр.../ Айзирәк Гәрәева,2011-2012. – URL: http://aiziryak.blogspot.ru/2013/12/blog-post.html (мөрәҗәгать итү вакыты: 07.03.2017)
17. Хатын-кыз концепты/ А.Х.Исламова, 2015. - URL: http://nsportal.ru/vuz/sotsiologicheskie-nauki/library/2015/02/12/khatyn-kyz-kontsepty (мөрәҗәгать итү вакыты: 07.03.2017)
18. Л.Хәбибуллина, Хатын-кыз язучы укучы йөрәгенә юлны ник яхшырак таба белә?/ Шәһри Казан, 2015. -URL: http://shahrikazan.com/tt/2015-01-22-07-49-54/2015-01-22-08-01-34/item/13328-hatyin-kyiz-yazuchyi-ukuchyi-yørəgenə-yul-taba-belə.html (мөрәҗәгать итү вакыты: 17.03.2017)

### Автор публикации

**Р. Р. Гаянова**. студент, Набережночелнинский государственный педагогический университет, email: railya.nurly@mail.ru

## FEMALE IMAGES IN WORKS OF Z. KADYROV

**R. Gayanova**
railya.nurly@mail.ru

**Naberezhnye Chelnrailya y State Pedagogical University, Naberezhnye Chelny, Russia**

***Abstract:*** *Features of stories by Z. Kadyrova. The concept of happiness of people. Heroes of works by Z. Kadyrova in the contexts of experiences and ideas. Attitude to books through reader interests*
***Keywords:*** *Z. Kadyrova, Tatar literature, features, images of women, collective image*

### Authors of the published work

**R. Gayanova,** bachelor, Naberezhnye Chelny State Pedagogical University, Russia. Email: railya.nurly@mail.ru

**Дата поступления 10.03.2018**